РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422071, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Кильдебяк, ул. Чулпаново, 20а
тел. (84362) 45-5-50

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЛДЕБӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422071, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Килдебәк авылы, Чулпан урамы, 20а йорт
тел. (84362) 45-5-50

e-mail: Kilb.sab@tatar.ru

№ 13 21.06.2024

КАРАР

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты нигезендә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ::

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган җирле салым суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

   1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

   2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

   3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 һәм (яки) 70 статьяларында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада физик затларның бурычы булуы.

2. Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советының «җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар буенча бурычларны һәм бу салымнар буенча штрафларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»15.05.2023 ел, №15 карары үз көчен югалткан дип танылсын.

3. Әлеге карарның рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә кергән дип санарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/kildebiak урнаштырырга.

5.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Килдебәк авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Заһидуллин